**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 24 » сентябрь 2018 ел № 80

Келәнче авыл җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елнын 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның гомуми принциплары” турындагы 131 номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум ” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авылы башкарма комитетының 24 сентябрь 2018 елда чыккан 10 номерлы “Җирле референдум үткәрү ” карары, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Советының 24 сентябрь 2018 елда чыккан 79 номерлы “Җирле референдум үтрәрү ” карары нигезендә,

Келәнче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Келәнче авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 2018 елның 18 ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә расларга:

2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, көндезге уку рәвеше буенча укучы студентлардан кала һәр кешедән 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме, һәм җыелган акчаларны, киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә билгеләнгән эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

* **Җирлек территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерү өчен:**
- җәйге-көзге чорда торак пунклары эчендә чүп үләннәрен чабу: Келәнче һәм Бәки авылларында
-чишмәләрне төзекләндерү: Келәнче авылында
*** Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- юлларны төзекләндерү : Келәнче авыл җирлегедә юлларга ком һәм вак таш салу.
- Келәнче һәм Бәки авылы юлларын кардан чистарту.
*** Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү:**
- яраксызга чыккан су трубаларын алыштыру һәм ватылган очракта яңа насос алу, суны карап торучы кешегә хезмәт хакы түләү өчен.
* **Каты коммуналь калдыкларны жыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру:**
-авыл җирлегендәге вакытлы каты коммуналь калдыкларны жыю урынын чистартып тору.”

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук “Идел таңнары” газетасында бастырырга һәм мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама

Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге”
Советы рәисе Д.А.Кадыров.